**Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по художественно-эстетическому направлению развития детей №91 «Журавушка»**

**"Торнакай» 91 нче балаларның сэнгати-эстетик танып-белүен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомүмүстерешле балалар бакчасы муниципаль бюджетлы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

2нче кечкенәләр төркемендә ачык шөгыль

# «Лунтик - әкиятенә сәяхәт»

Төзеде: тәрбияче

Фаттахова

Гөлчәчәк Абдулахатовна

**Максат:** “Лунтик” әкияте аша балаларның бөҗәкләр турындагы белемнәрен гомумиләштерү.

**Бурычлар**:

1) Балаларда бөҗәкләргә карата кызыксыну уяту;бөҗәкләр турындагы белемнәрен ныгыту. 5 эчендә предметларны санау күнекмәсен ныгыту, геометрик фигураларны кабатлау, никадәр- шул кадәр, уң - сул билгеләрен ныгыту;

2) Балаларның игътибарын, хыялана белүләрен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;

3) Ят әйберләргә карата уяу караш тәрбияләү; бер-беренә карата ярдәмчелек хисе тудыру.

**Төп белем бирү өлкәсе:** "Танып белү үсеше" .

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** "Социаль-коммуникатив үсеш" , "Физик үсеш" , "Сөйләм үсеше" .

**Методик алымнар һәм чаралар:** Әңгәмә**,** дидактик уен, сюрприз моменты, мактау**.**

**Җиһазлау**:

- Демонстрацион материал: “Лунтик” әкиятеннән төшерелгән рәсемнәр, бал корты сүрәте;

-Ковролинда: чәчәкләр, күбәләкләр ( зур - зәңгәр һәм кечкенә - сары), күбәләк корты (2);

-Таратма материаллар:киселгән геометрик фигуралар( түгәрәк (5), өчпочмак (5), квадрат (5); бал корты рәсемнәре (5), дидактик уен “Рәсемне җый” (2 балага 1);

-Тар һәм киң такта, су өчен зәңгәр тукыма, “Лунтик” төшерелгән сумка,

- Ноутбукта бал корты тавышы язмасы;

- Бүләк.

**Сүзлек өстендә эш:** Басма.

**Алдан үткәрелгән эш:** Бөҗәкләр турында әңгәмә, геометрик фигуралар белән уеннар, дидактик уен “Рәсемне җый”.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче:** Балалар, безгә кунаклар килде. Әйдәгез әле алар белән бергәләп исәнләшеп алыйк.

**Балалар:** Исәнмесез.

**Тәрбияче** Әйдәгез, түгәрәк ясап басыйк, кулларга-куллар тотынышыйк.

**Бергәләп:** Кулларга без тотындык,

Бер-беребезгә елмайдык.

Җылы китте кулларга,

Рәхәт булды дусларга.

**Тәрбияче**: Балалар кәефләрегез ничек?

**Балалар:**Бик әйбәт, шәп, күтәренке, күңелле.

**Тәрбияче:** Менә минем кәефем бик үк яхшы түгел. Нишләргә дә белмим: бакчага килгәч, бер ят сумка таптым. Кемнеке икән ул? Бәлки сезгә таныштыр? (балаларга Лунтик ясалган сумка күрсәтә)

**Балалар:** “Лунтик”ныкы

**Тәрбияче:** Шулай бугай шул. Ә нәрсә бар икән анда? Балалар, ят сумканы рөхсәттән башка ачырга ярыймы?

**Балалар:**Юк.

**Тәрбияче:** Нишләргә соң? Карагыз әле монда бер кәгазь кисәге эленеп тора. Карыйк әле. (укый) “ Бу сумканы ачырга рөхсәтем бар. Лунтик”. Ачырга ярыймы инде?

**Балалар:** Әйе.

**Тәрбияче:**Сумка эчендә хат бар . (укый) Исәнмесез балалар! Сезгә бу хатны Лунтик яза. Мин сезне әкияткә уйнарга чакырам.) “Лунтик” әкиятенә барабызмы, балалар?

**Балалар:** Барабыз.

**Тәрбияче:** Ә кемнәр көтәр икән безне анда?

**Балалар:** Чикерткә, камка, бал корты, күбәләкләр, үрмәкүч.

**Тәрбияче:** Бер сүз белән без аларны ничек атыйбыз?

**Балалар:** Бөҗәкләр.

**Тәрбияче:** Әйдәгез, бөҗәкләр янына!

Без бастык түгәрәккә(түгәрәкә басып)

Бергәләшеп уйнарбыз (кулга кул тотынышып)

Әкияти илгә барырбыз.

**Тәрбияче:** Менә килеп тә җиттек.

(бал корты тавышлары язмасы)

**Тәрбияче:** Балалар нинди тавыш ишетелә?

**Балалар:** Бал корты тавышлары ишетелә.

**Тәрбияче**: (бал корты төшкән рәсемне күрсәтеп) Бал кортлары нишлиләр?

**Балалар:** Бал җыялар, очалар, бызылдыйлар, чәчәктән-чәчәккә куналар.

**Тәрбияче:** Балалар, монда бал кортларына чәчәкләр бармы соң?

**Балалар:** Юк.

**Тәрбияче:** Әйдәгез бергәләп геометрик фигуралардан чәчәкләр ясыйбыз. Син, ... - түгәрәкләрдән, ... - квадратлардан, ... - өчпочмаклардан чәчәкләр ясарсыз. (дидактик уен “Геометрик чәчәкләр”)

**Тәрбияче:** Балалар чәчәкләр нинди төстә?

**Балалар:** Төрле-төрле төстә.

**Тәрбияче:** Түгәрәкләрдән төзелгән чәчәк нинди төстә?

**Балалар:** Түгәрәкләрдән төзелгән чәчәкләр сары төстә. (шулай ук квадрат, өчпочмак)

**Тәрбияче:** Кызыл чәчәктә ничә таҗ бар? ( 1Бала таҗларны саный).

**Тәрбияче:**Әйдәгез, бал кортларына ярдәм итик: никадәр чәчәк - шулкадәр бал котларын чәчәкләргә утыртабыз ( 1бала чәчәкләргә бал кортларын утырта)

**Тәрбияче:**Менә булдырдыгыз. Молодцы. Бал кортларына ярдәм иттек. Әйдәгез алга барабыз. Каршыбызда елга ага. Елга нинди?

**Балалар:** Елга озын, киң, күк төстә.

**Тәрбияче:** Безгә елгага басмыйча, икенче якка чыгарга кирәк. Елга аша ничек чыгырга мөмкин?

**Балалар:** Күпер салып чыгып була, яхта белән, пароход белән, көймә белән, сикереп чыгарга мөмкин.

**Тәрбияче:** Менә монда ике такта бар.  Алар нинди?

**Балалар:** Алар төрле: берсе -  тар, икенчесе - киң такта. (тәрбияче басманы куя)

**Тәрбияче:** Ә елга аша чыгар өчен кайсы  басма уңайлырак?

**Балалар:** Киң  басма .

**Тәрбияче:** Әйдәгез, балалар, елганың икенче ягына чыгабыз.

**Тәрбияче:** Менә бик матур аланга килеп чыктык. Малайлар - чикерткә булып сикереп, кызлар - күбәләкләр булып очып аланга урнашыгыз. (ковролин янына узалар)

**Тәрбияче:** Күрегез: күбәләкләр оча. Алар бертөрлеме?

**Балалар:** Юк, төрле-төрле.

**Тәрбияче:** Күбәләкләр нәрсәләр белән аерылалар?

**Балалар:** Төсләре белән: берсе – сары, икенчесе-зәңгәр. Берсе - зур һәм икенчесе - кечкенә.

**Тәрбияче:** Карагыз әле: аста урнашкан чәчәк астына кемдер качкан, кемдер бар сыман. ..., карагыз әле,  кем бар астагы чәчәктә ( аста урнашкан чәчәк артын карый, чәчәк артыннан күбәләк кортларын ала)

**Тәрбияче:** Кемнәр бу?

**Балалар:** Күбәләк кортлары.

**Тәрбияче:** Ә хәзер безгә күбәләк кортларын күбәләкләр янына урнаштырырга кирәк, чөнки алар тиздән күбәләккә әйләнәләр. ..., Пупсинны - сары күбәләкнең уң ягына урнаштыр, ..., Вупсинны -  зәңгәр күбәләкнең сул ягына урнаштыр (2 бала)

Молодцы! Күбәләкләргә ярдәм иттек: Һәрбер бөҗәкне үзләренең урыннарына урнаштырдык. Хәзер, балалар, сез дә үзегенең урыннарыгызга: өстәл артына утырабыз. (балалар үз урыннарына утыралар)

**Тәрбияче**: Өстәлдә кисек рәсемнәр бар, безгә шул рәсемнәрне җыярга кирәк. Рәсем өстәлдә берәү генә, сез бергәләп дус һәм тату булып аны җыясыз. (балалар рәсемне җыялар)

**Тәрбияче:** Молодцы! Рәсемнәргә карасак, Лунтикның дусларын күрәбез. Кемнәрне күрәбез?

**Балалар:** Үрмәкүчне, чикерткәне, камканы, кысланы, күбәләкләрне, күбәләк кортларын, кырмыскаларны күрәбез.

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, балалар. Инде бакчага кайтыр вакыт җитә. Әйдәгез минем белән. (коверга узалар).

**Тәрбияче:** Тагын ниндидер кәгазь кыштырдый бу сумкада (сумкадагы кәгазьне укый). “ Бу мин-Лунтик. Мин сезне көн саен айдан карап торам. Бүген сез минем дусларым белән уйнадыгыз. Молодцы! Булдырдыгыз. Сезгә истәлеккә үземнең сумкамны һәм бүләгемне калдырам. Ә бүләк сезнең самовар астында. Дус һәм тату булыгыз!”

**Тәрбияче:** Ай рәхмәт, Лунтик! Лунтик нәрсә дип язып калдырган?

**Балалар:** Үзенең сумкасын һәм бүләген калдырган. Дус һәм тату уйнагыз, дип язган. Молодцы, дигән Лунтик.

**Тәрбияче:** Кая соң безнең самовар?

**Балалар:** Самовар шкаф өстендә.

**Тәрбияче:** Менә-бүләк. Мозаика уены. Лунтикка нәрсә әйтергә кирәк?

**Балалар:** Рәхмәт.

**Тәрбияче:** Балалар, безнең кунакларыбызга да китәр вакыт җитте. Әйдәгез, алар белән саубуллашыйк.

**Балалар:** Саубулыгыз.

**Тәрбияче:** Ә без яңа уен белән танышыйк, тату булып уйныйк, ә Лунтик безгә айдан карап, сөенеп торыр.

## Кулланган әдәбият

1. “Математикага өйрәнәбез” (икенче кечкенәләр төркеме өчен) Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. Г.Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина, Ф.В.Хәзратова. Казан, Татарстан китап нәшрияты 2013.
2. “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе”. Методик кулланма. Казан, 2013
3. “Үстерешле уеннар”. Методик кулланма. З.М.Зарипова, Р.С.Исаева, Казан, 2013